РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 25 марты Кукмара ш. № 114

Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 04 июнедәге 66 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 04 июнедәге 66 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктта «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча Бердәм комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Җирле үзидарә органы Кукмара муниципаль районы Советына вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс уздыру турында үтенеч белән мөрәҗәгать, вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм аны биләүгә квалификация таләпләре турында мәгълүмат җибәрә. Вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә Конкурс Кукмара муниципаль Районы башлыгы карары

белән игълан ителә.»;

1.3. 2.1. пунктында «Район Башлыгы карары» сүзләрен «Совет карары» сүзләренә алмаштырырга»;

1.4. 3.5 пунктында «вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе (алга таба – җирле үзидарә органы җитәкчесе) исеменә гариза» сүзләрен «әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча шәхси гариза» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 3.6 пунктында «җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 4.2 пунктында «җирле үзидарә органы» сүзләрен «Кукмара муниципаль районы Советы» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 4.5 пунктында «җирле үзидарә органы» сүзләрен «Кукмара муниципаль районы Советы» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 4.6 пунктында «җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан» сүзләрен «Кукмара муниципаль районы Советы кадрлар хезмәте тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 4.9 пунктында:

беренче абзацта «җирле үзидарә органы җитәкчесе» сүзләрен «Кукмара муниципаль районы Башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «җирле үзидарә органы» сүзләрен «Кукмара муниципаль районы Советы» сүзләренә алмаштырырга».

1.10. 1 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев